| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Казан ш. № 5-15/тэ

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Кулланучыларга «Татэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык энергиясенә 2016-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 5-47/тэ номерлы карарының 1нче кушымтасындагы 1.3 пунктына үзгәрешләр кертү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә, шулай ук «КАМАЗ-Энерго» ҖЧҖ җылылык энергиясен тапшыру хезмәтен күрсәтү буенча җайга салына торган эшчәнлеген туктатуына бәйле рәвештә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасының тарифлар буенча дәүләт комитетының «Кулланучыларга «Татэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан 2016-2018 елларга бирелә торган җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 5-47/тэ номерлы карарының (Татарстан Республикасының тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 16 декабрендәге 5-67/тэ номерлы, 2017 елның 15 декабрендәге 5-83/тэ номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1нче кушымтасындагы 1.3 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләрен «Көнбатышка таба китүче җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев